| | |
|---|---|
| ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ «ЗАЙ-КАРАТАЙСКОЕ СЕЛЬСКОЕ ПОСЕЛЕНИЕ» ЛЕНИНОГОРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЛЕНИНОГОРСК МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ «ЗӘЙ-КАРАТАЙ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ» МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ |

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2025 елның 21 июле №38

Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районының «Зәй-Каратай авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районының» Зәй-Каратай авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясендә терекөмешле лампаларның туплану урынын билгеләү, кулланучыларга аның урнашуы турында мәгълүмат бирү турында» 2023 елның 9 мартындагы 13 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Дәүләт экология мониторингы (әйләнә-тирә мохитнең дәүләт мониторингы) турында Нигезләмәне раслау хакында» 2024 елның 14 мартындагы 300 номерлы карарын үтәү йөзеннән, Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районының «Зәй-Каратай авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставына таянып, Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районының «Зәй-Каратай авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1.Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районының «Зәй-Каратай авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районының «Зәй-Каратай авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясендә терекөмешле лампаларның туплану урынын билгеләү, кулланучыларга аның урнашуы турында мәгълүмат бирү турында» 2023 елның 9 мартындагы 13 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

түбәндәге эчтәлекле 1.1 пункт белән тулыландырырга:

«1.1 Кулланучыларга терекөмешле лампалар туплану урыннарының урнашуы турында мәгълүматны әйләнә-тирә мохит торышының федераль дәүләт мәгълүмат системасында урнаштыру юлы белән хәбәр итү.».

2. Әлеге карарны түбәндәге адрес буенча урнашкан мәгълүмат стендларында халыкка җиткерергә: ТР, Лениногорск муниципаль районы, Зәй-Каратай авылы, Совет урамы, 99; Үзбәк авылы, Луговая, 2нче йорт адресы буенча урнашкан мәгълүмат стендларында игълан итәргә, Лениногорск муниципаль районының рәсми сайтында (https://leninogorsk.tatar.ru) «Авыл җирлекләре» бүлегендә һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталында (https://pravo.tatarstan.ru) бастырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплыгымда калдырам.

Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы
«Зәй-Каратай авыл җирлеге»
муниципаль берәмлеге башлыгы,
Совет рәисе М.И. Идиятова